Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авыл Советы
КАРАРЫ

14 декабрь 2023 ел — № 85

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Яңа Кәшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 25 декабрендәге 40 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турындагы карарына үзгәрешләр кертү

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше, Әлмәт муниципаль районының «Яңа Кәшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан торак пунктларга тапшыру турында» 2022 елның 12 декабрендәге 182 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары, Әлмәт муниципаль районы Башлыгының 2023 елның 24 июлендәге 130 номерлы карары нигезендә узган «Гавами тыңлаулар билгеләү турында» 2023 елның 16 августындагы 7091 и номерлы («Альметьевский вестник» газетасының 2023 елның 17 августындагы 33 номерлы санында басылган) гавами тыңлаулар нәтиҗәләре бәяләмәсе нигезендә,

Яңа Кәшер авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Яңа Кәшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 25 декабрендәге 40 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турындагы карарына» (2022 елның 26 маендагы 43 номерлы, 2022 елның 28 сентябрендәге 49 номерлы, 2023 елның 7 апрелендәге 64 номерлы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 4 статья 4 пунктчаның 9 абзацында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

- 19 статьяның 2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «җир асты байлыкларыннан файдалануны гамәлгә ашыру.»;

- 19 статьяның 3 пунктында «Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 1, 3 һәм 4 пунктчаларында каралган максатларда гавами сервитут чикләре» сүзләрен «Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 1, 3 һәм 4.1 пунктчаларында каралган максатларда, шулай ук


Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 6 пунктчасы нигезендә инженерлык корылмалары кишәрлекләрен (өлешләрен) реконструкцияләү максатларында билгеләнә торган гавами сервитут чикләре» сүзләренә алмаштырырга;

- 19 статья 4 пунктның 1 пунктчасында «1, 3 һәм 4» пунктчалары сүзләрен « 1, 3 һәм 4.1» пунктчалары белән алмаштырырга


- 27 статья 7 пунктының 18 абзацында «туфракны ашламалау өчен агынты суларны куллану» дигән сүзләрне «туфракның уңдырышлылыгын арттыру максатларында агынты суларны куллану» дигән сүзләр белән алыштырырга;

- IV-V классы куркыныч җитештерү-коммуналь объектларның территориаль зонасын киметү (ПК-1), шәхси торак йортларның территориаль төзелеш зонасын арттыру (Ж1) өлешендә шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә:

Гамәлдәге торышы




Проектта каралу




2.Әлеге карарны торак пункт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Яңа Кәшер авылы, Тавабилов урамы, 153 йорт, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Яңа Кәшер авылы
җирлеге Башлыгы

Л.М. Гиниятуллина